# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 21 ноябре №

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 - ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылындагы гражданнар җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ике ташламага ия булучыдан кала, 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Рус Борнашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (билгеләнгән урынга илтеп җиткереп, асфальт гранулат сатып алу).

Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына, Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районының
Куралово авыл җирлеге башлыгы Р. Е. Тарасов